УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О порядке ведения реестров государственных гражданских служащих в государственных органах Республики Татарстан и Реестра государственных гражданских служащих Республики Татарстан»**

В целях совершенствования деятельности по ведению реестров государственных гражданских служащих в государственных органах Республики Татарстан и Реестра государственных гражданских служащих Республики Татарстан **постановляю:**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 23 октября 2006 года № УП-431 «О порядке ведения реестров государственных гражданских служащих в государственных органах Республики Татарстан и Реестра государственных гражданских служащих Республики Татарстан» следующие изменения:

а) в пункте 2 слова «Департаментом по делам государственных служащих при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан»;

б) пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3. Департаменту государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан оказывать методическую и консультативную помощь кадровым службам государственных органов Республики Татарстан по вопросам ведения реестров государственных гражданских служащих Республики Татарстан в государственных органах и обеспечивать координацию их ведения в государственной информационной системе Республики Татарстан «Единая информационная система кадрового состава государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан.»;

в) Положение о порядке ведения реестров государственных гражданских служащих в государственных органах Республики Татарстан и Реестра государственных гражданских служащих Республики Татарстан изложить в новой редакции согласно приложению.

2. Рекомендовать органам местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан руководствоваться настоящим Указом при разработке муниципальных правовых актов, определяющих порядок ведения реестров муниципальных служащих в муниципальном образовании.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
29 января 2016 года
№ УП-61

Утверждено
Указом Президента
Республики Татарстан

от «29 » января 2016 года

№ УП - 61

**Положение**
**о порядке ведения реестров государственных гражданских служащих в государственных органах Республики Татарстан и Реестра государственных гражданских служащих Республики Татарстан**

I. Общие положения

1. Настоящее Положение в соответствии с Федеральным законом от 27 мая 2003 года № 58-ФЗ «О системе государственной службы Российской Федерации», Федеральным законом от 27 июля 2004 года № 79-ФЗ «О государственной гражданской службе Российской Федерации» и Законом Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» определяет содержание и порядок ведения реестров государственных гражданских служащих в государственных органах Республики Татарстан и Реестра государственных гражданских служащих Республики Татарстан.

2. Реестры государственных гражданских служащих Республики Татарстан в государственных органах Республики Татарстан формируются на основе сведений из личных дел государственных гражданских служащих Республики Татарстан (далее – государственные служащие), замещающих должности государственной гражданской службы Республики Татарстан (далее – государственная служба) в государственных органах Республики Татарстан (далее – государственные органы).

3. Реестры государственных служащих в государственных органах образуют Реестр государственных гражданских служащих Республики Татарстан (далее – Реестр государственных служащих Республики Татарстан), который представляет собой сводный перечень сведений о государственных служащих в государственных органах.

4. Сведения, внесенные в реестры государственных служащих в государственных органах и Реестр государственных служащих Республики Татарстан, в случаях, установленных федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, относятся к сведениям, составляющим государственную тайну, а в иных случаях – к сведениям конфиденциального характера и подлежат защите в соответствии с законодательством Российской Федерации.

5. Реестры государственных служащих в государственных органах и Реестр государственных служащих Республики Татарстан ведутся в государственной информационной системе «Единая информационная система кадрового состава государственной гражданской службы Республики Татарстан и муниципальной службы в Республике Татарстан» (далее – Информационная система), а также на бумажном носителе с обеспечением защиты содержащейся в них информации от несанкционированного доступа, уничтожения, модифицирования, блокирования, копирования, предоставления, распространения, а также от иных неправомерных действий.

## II. Ведение реестров государственных служащих в государственных органах и Реестра государственных служащих Республики Татарстан

6. Реестр государственных служащих в государственном органе ведется подразделением государственного органа по вопросам государственной службы и кадров (далее – кадровая служба) в Информационной системе и на бумажном носителе.

7. Реестр государственных служащих в государственном органе, сформированный по состоянию на 1 января текущего года на бумажном носителе и утвержденный руководителем государственного органа (лицом, замещающим государственную должность Республики Татарстан), представляется в двух экземплярах в Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан (далее – Департамент) не позднее 15 февраля текущего года.

8. Формирование и ведение Реестра государственных служащих Республики Татарстан осуществляется Департаментом в Информационной системе на основе представленных в ней реестров государственных служащих в государственных органах.

9. Формы реестра государственных служащих в государственном органе и Реестра государственных служащих Республики Татарстан утверждаются Департаментом и размещаются в Информационной системе.

10. Реестр государственных служащих Республики Татарстан и реестры государственных служащих в государственных органах включают в себя сведения о:

персональных данных государственного служащего;

наименовании государственного органа, в котором государственный служащий проходит государственную службу;

наименовании структурного подразделения данного государственного органа;

наименовании замещаемой государственным служащим должности государственной службы в соответствии с Реестром должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан;

включении государственного служащего в кадровый резерв на государственной службе (дата включения в кадровый резерв, наименование

должности, основание для включения в кадровый резерв, основание для исключения из кадрового резерва).

11. Персональные данные государственного служащего включают в себя сведения:

о фамилии, имени, отчестве государственного служащего;

о дате рождения;

о профессиональном образовании (наименование образовательной организации, номер и дата диплома, специальность и квалификация);

о прохождении военной службы;

о прохождении профессиональной переподготовки (наименование образовательной организации, дата окончания обучения, наименование программы, вид и номер итогового документа);

о повышении квалификации (наименование образовательной организации, дата окончания обучения, наименование программы, вид и номер итогового документа);

об ученой степени (наименование ученой степени, дата присвоения);

об ученом звании (наименование ученого звания, дата присвоения);

об общем трудовом стаже, рассчитанном в годах, месяцах, днях;

о стаже государственной службы, исчисляемом в годах, месяцах, днях;

о прохождении аттестации (дата проведения аттестации, решение аттестационной комиссии);

о классном чине (присвоенный классный чин, дата и номер акта о его присвоении);

о государственных наградах и иных наградах (вид награды, дата награждения);

о прохождении конкурса на замещение вакантной должности государственной службы (если гражданин назначен на должность по результатам конкурса);

о служебном контракте (вид, дата заключения служебного контракта, срок его действия, дата внесения в него изменений).

Настоящий перечень персональных данных государственных служащих является исчерпывающим и применяется исключительно по отношению к реестрам государственных служащих в государственных органах и Реестру государственных служащих Республики Татарстан.

12. Сведения о гражданах, поступающих на государственную службу, вносятся в реестры государственных служащих в государственных органах в течение двух рабочих дней со дня их назначения на должности государственной службы на основании актов руководителей государственных органов (лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан) о назначении.

13. При назначении государственного служащего на другую должность в этом же государственном органе сведения о его назначении на должность государственной службы вносятся в реестр государственных служащих в государственном органе в течение двух рабочих дней со дня его назначения на должность государственной службы на основании акта руководителя

государственного органа (лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан) о назначении.

14. Основанием для исключения сведений о государственном служащем из реестра государственных служащих в государственном органе и из Реестра государственных служащих Республики Татарстан является его увольнение, назначение на государственную должность Республики Татарстан или должность, не являющуюся должностью государственной службы, смерть (гибель), а также признание лица безвестно отсутствующим или умершим решением суда, вступившим в законную силу.

Основанием для исключения сведений о государственном служащем из реестра государственных служащих в государственном органе является также его назначение на должность государственной службы в другом государственном органе.

Сведения о государственном служащем по указанным основаниям исключаются из реестра государственных служащих в государственном органе в день, следующий за днем увольнения, назначения на должность государственной службы в другом государственном органе, назначения на государственную должность Республики Татарстан или должность, не являющуюся должностью государственной службы, смерти (гибели), или в день вступления в законную силу соответствующего решения суда.

15. Сведения о соответствующих изменениях в реестре государственных служащих в государственном органе вносятся в Информационную систему и направляются в Департамент.

16. Сведения о государственных служащих, проходивших государственную службу в государственных органах и исключенных из реестров государственных служащих в государственных органах, передаются в архив в соответствии с законодательством.

17. Споры, связанные с ведением реестров государственных служащих в государственных органах и Реестра государственных служащих Республики Татарстан, рассматриваются в соответствии с законодательством комиссиями по служебным спорам и судом.

## III. Контроль за ведением реестров государственных служащих в государственных органах

18. Контроль за ведением реестров государственных служащих в государственных органах обеспечивает руководитель государственного органа (лицо, замещающее государственную должность Республики Татарстан). Контроль осуществляется в форме проверки наличия личных дел и их состояния, сверки сведений, содержащих персональные данные государственных служащих, со сведениями, содержащимися в реестре государственных служащих в государственном органе.

Факт сверки сведений отражается в соответствующем акте.

19. Государственные служащие, на которых возложены обязанности по формированию и ведению реестров государственных служащих в

государственных органах и Реестра государственных служащих Республики Татарстан, несут ответственность в соответствии с законодательством за разглашение сведений конфиденциального характера и сведений, составляющих государственную тайну.

## IV. Представление сведений из реестров государственных служащих в государственных органах, Реестра государственных служащих Республики Татарстан и хранение реестров

20. Сведения из Реестра государственных служащих Республики Татарстан представляются Департаментом Президенту Республики Татарстан и Руководителю Аппарата Президента Республики Татарстан.

21. Реестры государственных служащих в государственных органах, изменения к ним хранятся в Информационной системе, а также на бумажных носителях в соответствующих государственных органах.

22. Реестр государственных служащих Республики Татарстан хранится в Информационной системе и на бумажном носителе в Департаменте. Реестр государственных служащих Республики Татарстан на бумажном носителе формируется по состоянию на 1 января текущего года.

23. Реестры государственных служащих в государственных органах и Реестр государственных служащих Республики Татарстан на бумажных носителях хранятся в режиме, исключающем несанкционированный доступ к ним, в течение 5 лет (как документы строгой отчетности), после чего передаются на хранение в архив в соответствии с законодательством Российской Федерации.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2006 елның 23 октябрендәге ПУ-431 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына Татарстан Республикасы дәүләт органнары кадрлар хезмәтләренә дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару мәсьәләләре буенча методик һәм консультатив ярдәм күрсәтергә һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында аларны алып баруларын координацияләүне тәэмин итәргә»;

в) Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларны эшләгәндә әлеге Указга нигезләнеп гамәл кылуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 29 гыйнвар
№ ПУ-61

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «29» гыйнварындагы
ПУ-61 номерлы Указы
белән расланды

**Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмәдә «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» 2003 елның 27 маендагы 58-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестры эчтәлеген һәм аларны алып бару тәртибе билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органнарындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрлары Татарстан Республикасы дәүләт органнарында (алга таба – дәүләт органнары) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) шәхси эшләрендәге мәгълүматлар нигезендә формалаштырыла.

3. Дәүләт органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрлары Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестры) тәшкил итә һәм ул дәүләт органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре турында җыелма мәгълүматлар исемлегеннән гыйбарәт була.

4. Дәүләт органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына кертелгән мәгълүматлар федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булып тора, ә башка очракларда – конфеденциаль характердагы мәгълүматларны тәшкил итә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә саклана.

5. Дәүләт органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестры «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Мәгълүмат системасы), шулай ук аларда булган мәгълүматны рөхсәтсез кулланудан, юкка чыгарудан, модификацияләүдән, тыю салудан, күчермәләр алудан, бирүдән, таратудан, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклау тәэмин ителгән кәгазь чыганакта алып барыла.

## II. Дәүләт органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару

6. Дәүләт органында дәүләт хезмәткәрләре реестры дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе (алга таба – кадрлар хезмәте) тарафыннан Мәгълүмат системасында, шулай ук дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан расланучы кәгазь чыганакта алып барыла.

7. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләренең мәгълүмат системасында агымдагы елның 1 гыйнварына формалаштырылган реестры кәгазь чыганакта ике нөсхәдә агымдагы елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча Департаментка тапшырыла.

8. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын формалаштыру һәм алып бару Мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан дәүләт органнарындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрлары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестры формалары Департамент тарафыннан раслана һәм Мәгълүмат системасында урнаштырыла.

10. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына һәм дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрларына түбәндәгеләр турындагы мәгълүматлар кертелә:

дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәте уза торган дәүләт органы атамасы;

әлеге дәүләт органының структур бүлекчәсе атамасы;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры нигезендә дәүләт хезмәткәре били торган дәүләт хезмәте вазыйфасының атамасы;

дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтендә кадрлар резервына кертү (кадрлар резервына кертү вакыты, вазыйфаның атамасы, кадрлар резервына кертүне нигезләү, кадрлар резервыннан чыгаруны нигезләү);

дәүләт хезмәткәре турында шәхси мәгълүматлар.

11. Дәүләт хезмәткәре турында шәхси мәгълүматларга түбәндәге белешмәләр кертелә:

дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме турында;

туган елы турында;

һөнәри белеме турында (мәгариф оешмасының атамасы, диплом номеры һәм датасы, белгечлеге һәм квалификациясе);

хәрби хезмәт узуы турында;

яңадан һөнәри әзерлек узуы турында (мәгариф оешмасының атамасы, укуны тәмамлау вакыты, программаның атамасы, йомгаклау документының төре һәм номеры);

квалификациясен күтәрүе турында (мәгариф оешмасының атамасы, укуны тәмамлау вакыты, программаның атамасы, йомгаклау документның төре һәм номеры);

гыйльми дәрәҗәсе турында (гыйльми дәрәҗәнең атамасы, бирү вакыты);

гыйльми исеме турында (гыйльми исемнең атамасы, бирү вакыты);

елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән гомуми хезмәт стажы;

елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән дәүләт хезмәте стажы;

аттестацияләү узуы турында (аттестация уздырылу датасы, аттестация комиссиясе карары);

класслы чины турында (бирелгән класслы чин, датасы һәм аны бирү турындагы актның номеры);

дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләре турында (бүләк төре, бүләкләү датасы);

дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс узуы турында (әгәр граждан әлеге вазыйфага конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнсә);

хезмәт контракты турында (хезмәт контрактының төре, аны төзү вакыты, аның гамәлдә булу вакыты, үзгәрешләр кертү датасы).

Дәүләт хезмәткәре турында әлеге шәхси мәгълүматлар исемлеге тулы һәм фәкать Татарстан Республикасының дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрларында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестрында гына куллану өчен билгеләнә.

12. Дәүләт хезмәтенә эшкә керүче гражданнар турында мәгълүматлар дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрына алар дәүләт органы җитәкчеләренең (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның) вазыйфага билгеләп кую турындагы актлары нигезендә дәүләт хезмәте вазыйфаларына билгеләнгән көннән соң ике эш көне дәвамында кертелә.

13. Дәүләт хезмәткәрен шушы ук дәүләт органында башка вазыйфага билгеләгәндә аны дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләү хакындагы мәгълүматлар дәүләт органындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрына дәүләт органы җитәкчесенең (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның) вазыйфага билгеләү турындагы акты нигезендә аны дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләгән көннән соң ике эш көне дәвамында кертелә.

14. Дәүләт хезмәткәре турында мәгълүматларны дәүләт органындагы дәүләт хезмәткәрләре реестрыннан һәм Татарстан Республикасы дәүләт

хезмәткәрләре реестрыннан төшереп калдыру өчен аны эштән азат итү, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына яисә дәүләт хезмәтенә кермәгән вазыйфага билгеләп кую, аның үлеме (һәлак булуы), шулай ук үз көченә кергән суд карары нигезендә аны хәбәрсез югалган яисә вафат булган дип тану нигез булып тора.

Дәүләт хезмәткәрен башка дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп кую шулай ук аның турында мәгълүматларны дәүләт органында дәүләт хезмәткәрләре реестрыннан төшереп калдыру өчен нигез булып тора.

Күрсәтелгән сәбәпләр нигезендә дәүләт хезмәткәре турында мәгълүматлар дәүләт органында дәүләт хезмәткәрләре реестрыннан ул эштән азат ителгән, башка дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куелган, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына яисә дәүләт хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфага билгеләп куелган, үлгән (һәлак булган) көннән соң икенче көнне яисә дәүләт органы җитәкчесенең (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның) реестрдан тиешле мәгълүматларны төшереп калдыру турындагы акты нигезендә суд карары үз көченә кергән көннән төшереп калдырыла.

15. Дәүләт органында дәүләт хезмәткәрләре реестрында тиешле үзгәрешләр турындагы мәгълүматлар Департаментка дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан Мәгълүмат системасында кертелә һәм җибәрелә.

16. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәте үткән һәм дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрыннан төшереп калдырылган дәүләт хезмәткәрләре турында мәгълүматлар законнар нигезендә архивка тапшырыла.

17. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестрын алып бару белән бәйле бәхәсләр законнар нигезендә хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр һәм суд тарафыннан карала.

## III. Дәүләт органнарында граждан хезмәткәрләре реестрларын алып баруны контрольдә тоту

18. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрын алып баруны контрольдә тоту дәүләт органы җитәкчесе (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат) тарафыннан тәэмин ителә. Контрольдә тоту шәхси эшләрнең булуы һәм аларның торышы, дәүләт хезмәткәрләре турында шәхси мәгълүматлар кертелгән белешмәләрне дәүләт органында дәүләт хезмәткәрләре реестрындагы белешмәләр белән чагыштыру рәвешендә тормышка ашырыла.

Белешмәләрне чагыштыру факты тиешле актта теркәлә.

19. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестрын формалаштыру һәм алып бару вазыйфалары йөкләнгән дәүләт хезмәткәрләре конфиденциаль

характердагы мәгълүматларны һәм дәүләт сере булган мәгълүматларны тараткан өчен законнар нигезендә җаваплы була.

## IV. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрлары, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестры буенча мәгълүматлар бирү һәм реестрларны саклау

20. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестры буенча мәгълүматлар Департамент тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә бирелә.

21. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрлары һәм аларга кертелгән үзгәрешләр Мәгълүмат системасында, шулай ук тиешле дәүләт органнарында кәгазь чыганакта саклана.

22. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре реестры Мәгълүмат системасында, шулай ук агымдагы елның 1 гыйнварына кәгазь чыганакта Департаментта саклана.

23. Дәүләт органнарында дәүләт хезмәткәрләре реестрлары һәм Татарстан Республикасының дәүләт хезмәткәрләре реестры кәгазь чыганакларда рөхсәтсез кереп булмый торган режимда һәм, катгый исәп-хисап документлары буларак, 5 ел дәвамында саклана, аннан соң Россия Федерациясе законнары нигезендә, саклау өчен архивка тапшырыла.